| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

# О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О мерах по обеспечению функционирования в Республике Татарстан Государственной системы регистрации (учета) избирателей, участников референдума в Российской Федерации»

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 1 марта 2006 года № УП-78 «О мерах по обеспечению функционирования в Республике Татарстан Государственной системы регистрации (учета) избирателей, участников референдума в Российской Федерации» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 29 августа 2007 года № УП-472, от 8 февраля 2008 года № УП-55, от 27 августа 2010 года № УП-574, от 9 сентября 2013 года № УП-868, от 10 апреля 2014 года № УП-350, от 10 июля 2017 года № УП-611 и от 14 марта 2018 года № УП-231) следующие изменения:

а) в Указе:

в преамбуле цифры «134/973-2» заменить цифрами «134/973-II»;

в пункте 1:

в абзаце первом:

слова «органами ЗАГС,» исключить;

слова «пунктами 2.7 - 2.9» заменить словами «пунктами 2.7, 2.9»;

дополнить абзацем следующего содержания:

«Руководителям исполнительных комитетов муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан обеспечить передачу сведений, указанных в пунктах 2.7–2.11 Положения, в Центральную избирательную комиссию Республики Татарстан для формирования и ведения Регистра избирателей, участников референдума 10 числа каждого месяца, а за 10 и менее дней до дня голосования – ежедневно в порядке, который утверждается Центральной избирательной комиссией Республики Татарстан.»;

в пункте 4 слова «начальнику Управления ЗАГС Кабинета Министров Республики Татарстан,» исключить;

б) сроки представления органами учета населения сведений о гражданах Российской Федерации руководителям исполнительных комитетов муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан для регистрации (учета) избирателей, участников референдума, а также вид информационных носителей, на которых они представляются, изложить в новой редакции согласно приложению № 1;

в) состав рабочей группы по координации деятельности Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, органов исполнительной власти Республики Татарстан, иных государственных органов и руководителей исполнительных комитетов муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан при осуществлении регистрации (учета) избирателей, участников референдума и установлении численности зарегистрированных избирателей, участников референдума изложить в новой редакции согласно приложению № 2.

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
04 июня 2021 года
№ УП-435

Приложение № 1
к Указу Президента
Республики Татарстан

от « 04 » июня 2021 года

№ УП-435

**Сроки представления органами учета населения сведений о гражданах Российской Федерации руководителям исполнительных комитетов муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан для регистрации (учета) избирателей, участников референдума, а также вид информационных носителей, на которых они представляются**

| Органы учета населения | Вид муниципального образования | Периодичность | | Вид информационного носителя* |
|---|---|---|---|---|
| | | при проведении выборов, референдумов | иные периоды | |
| Управление по вопросам миграции Министерства внутренних дел по Республике Татарстан | Городские округа и муниципальные районы | Еженедельно, по средам, за 10 и менее дней до дня голосования – ежедневно | Ежемесячно, 10 числа | Электронный машиночитаемый носитель** |
| Военные комиссариаты | Городские округа и муниципальные районы | Еженедельно, по средам, за 10 и менее дней до дня голосования – ежедневно | Март, июнь, сентябрь, декабрь, 10 числа, а также по завершении призыва | Бумажный носитель или электронный машиночитаемый носитель*** |

Примечания:

* Под информационным носителем понимается бумажный носитель, электронный машиночитаемый носитель (флеш-накопитель, дискета, оптический диск или внешний жесткий диск).

** Сведения представляются по форме согласно приложению № 1 к Положению о Государственной системе регистрации (учета) избирателей, участников референдума в Российской Федерации, утвержденному постановлением Центральной избирательной комиссии Российской Федерации от 6 ноября 1997 года № 134/973-II (далее – Положение), а также в виде электронного файла в формате согласно приложению № 15 к Положению.

*** Сведения представляются по форме согласно приложению № 3 к Положению.

Приложение № 2
к Указу Президента
Республики Татарстан

от « 04 » июня 2021 года

№ УП- 435

**Состав**
**рабочей группы по координации деятельности Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, органов исполнительной власти Республики Татарстан, иных государственных органов и руководителей исполнительных комитетов муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан при осуществлении регистрации (учета) избирателей, участников референдума и установлении численности зарегистрированных избирателей, участников референдума**

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Премьер-министр Республики Татарстан, руководитель рабочей группы |
| Кондратьев Андрей Станиславович | Председатель Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан, заместитель руководителя рабочей группы (по согласованию) |
| Гараев Раиль Рузалевич | заместитель Руководителя Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан – начальник Управления по координации взаимодействия органов исполнительной власти Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан |
| Гарипов Ильнур Махмутович | заместитель Руководителя Аппарата Президента Республики Татарстан – начальник Управления по работе с территориями Президента Республики Татарстан |
| Глухова Лариса Юрьевна | начальник Государственно-правового управления Президента Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Нигматуллина Гульшат Радифовна | начальник Управления записи актов гражданского состояния Кабинета Министров Республики Татарстан |
| Погодин Сергей Николаевич | военный комиссар Республики Татарстан (по согласованию) |
| Салихов Зявдат Миргазямович | начальник Управления Судебного департамента в Республике Татарстан (по согласованию) |
| Хайруллин Айрат Ринатович | министр цифрового развития государственного управления, информационных технологий и связи Республики Татарстан |
| Хиалеев Эдуард Данилович | начальник Управления Федеральной службы исполнения наказаний по Республике Татарстан (по согласованию) |
| Хохорин Артем Валерьевич | Министр внутренних дел по Республике Татарстан (по согласованию) |

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Россия Федерациясендә сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәү (исәпкә алу) дәүләт системасының Татарстан Республикасында эшләвен тәэмин итү чаралары турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Россия Федерациясендә сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәү (исәпкә алу) дәүләт системасының Татарстан Республикасында эшләвен тәэмин итү чаралары турында» 2006 елның 1 мартындагы ПУ-78 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 29 августындагы ПУ-472 номерлы, 2008 елның 8 февралендәге ПУ-55 номерлы, 2010 елның 27 августындагы ПУ-574 номерлы, 2013 елның 9 сентябрендәге ПУ-868 номерлы, 2014 елның 10 апрелендәге ПУ-350 номерлы, 2017 елның 10 июлендәге ПУ-611 номерлы һәм 2018 елның 14 мартындагы ПУ-231 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Указда:

преамбулада «134/973-2» саннарын «134/973-II» саннарына алмаштырырга;

1 пунктта:

беренче абзацта: «Гражданлык хәле актларын язу (ЗАГС) органнары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

«2.7 - 2.9 пунктларында каралган» сүзләрен «2.7, 2.9 пунктларында каралган» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары җитәкчеләренә Нигезләмәнең 2.7–2.11 пунктларында күрсәтелгән белешмәләрне Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә Сайлаучылар, референдумда катнашучылар регистрын булдыру һәм алып бару өчен һәр айның 10 числосында, ә тавыш бирү көненә кадәр 10 һәм аннан да азрак көн кала һәр көн саен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе раслый торган тәртиптә тапшыруны тәэмин итәргә.»;

4 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС Идарәсе башлыгы,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) халык исәбен алу органнары тарафыннан сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәү (исәпкә алу) өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләренә Россия Федерациясе гражданнары турында мәгълүмат бирү срокларын, шулай ук мәгълүмат язылган чыганакның төрен 1 кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

в) сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәгәндә (исәпкә алганда) һәм теркәлгән сайлаучыларның, референдумда катнашучыларның санын билгеләгәндә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, башка дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре эшчәнлеген координацияләү буенча эш төркеме составын 2 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 04 июнь
№ ПУ-435

Татарстан Республикасы
Президентының
2021 елның « 04 » июнендәге
ПУ- 435 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Халык исәбен алу органнары тарафыннан сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәү (исәпкә алу) өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләренә Россия Федерациясе гражданнары турында мәгълүмат бирү сроклары, шулай ук мәгълүмат язылган чыганакның төре**

| Халыкны исәпкә алу органнары | Муниципаль берәмлекнең төре | Мәгълүмат тапшыру вакыты | | Мәгълүмат язылган чыганак төре* |
|---|---|---|---|---|
| | | Сайлаулар, референдумнар уздырганда | Башка чорларда | |
| Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министр-лыгының Миграция мәсьәләләре идарәсе | Шәһәр округлары һәм муниципаль районнар | Атна саен, чәршәмбе көнне, тавыш бирү көненә кадәр 10 һәм аннан да азрак көн кала – көн саен | Ай саен, 10 нчы числода | Машинада укыла торган электрон чыганакта ** |
| Хәрби комиссариатлар | Шәһәр округлары һәм муниципаль районнар | Атна саен, чәршәмбе көнне, тавыш бирү көненә кадәр 10 һәм аннан да азрак көн кала – көн саен | Март, июнь, сентябрь, декабрь, 10 нчы числода, шулай ук хәрби хезмәткә чакыру тәмамлангач | Кәгазьдә яисә машинада укыла торган электрон чыганакта *** |

Искәрмәләр:

* Мәгълүмат язылган чыганак дигәндә, кәгазь чыганак, машинада укыла торган электрон чыганак күздә тотыла (флеш-туплагыч, дискета, оптик диск яки тышкы каты диск).

** Белешмәләр Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенең 1997 елның 6 ноябрендәге 134/973-II номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәүнең (исәпкә алуның) дәүләт системасы турындагы нигезләмәнең (алга таба – Нигезләмә) 1 нче кушымтасында бирелгән формада, шулай ук Нигезләмәгә 15 нче кушымтада бирелгән форматта электрон файл рәвешендә тапшырыла.

*** Белешмәләр Нигезләмәгә 3 нче кушымтада бирелгән форма буенча тапшырыла.

Татарстан Республикасы
Президентының
2021 елның «04» июнендәге
ПУ-435 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәгәндә (исәпкә алганда) һәм теркәлгән сайлаучыларның, референдумда катнашучыларның санын билгеләгәндә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, башка дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре эшчәнлеген координацияләү буенча эш төркеме составы**

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, эш төркеме җитәкчесе |
| Кондратьев Андрей Станиславович | Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе, эш төркеме җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Гәрәев Раил Рузәл улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Башкарма хакимият органнары хезмәттәшлеген координацияләү идарәсе башлыгы |
| Гарипов Илнур Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы |
| Глухова Лариса Юрьевна | Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Нигъмәтуллина<br>Гөлшат Рәдиф кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы |
| Погодин<br>Сергей Николаевич | Татарстан Республикасы хәрби комиссары (килешү буенча) |
| Салихов<br>Җәүдәт Миргазәм улы | Суд департаментының Татарстан Республикасындагы идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Хәйруллин<br>Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры |
| Хиялиев<br>Эдуард Данил улы | Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Хохорин<br>Артем Валерьевич | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры (килешү буенча) |